


**ХЕЗМӘТ БАЗАРЫ**

Илдә нинди белгечләргә кытлык бар?

> 15



**ГРИПП КИЛӘ!**

Белгечләр алдан хәстәрен күрергә өнди

> 16



**ИЛДАР ЯГЪФӘРОВ:**

«Хәзер шундый вакыт: бөтен фильмнарны да кинозалларга чыгарырга мөмкинлек бар»


> 18


# ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 178 (28951) | Җомга | 2 декабрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

# УТТАН АЛЫП, СУГА САЛМА...

## 1 ДЕКАБРЬДӘН КОММУНАЛЬ ХЕЗМӘТЛӘРГӘ БӘЯЛӘР АРТТЫ

**Кыйммәтләнде! Моны барыннан да бигрәк Чаллы, Түбән Кама, Азнакай, Зәй кебек шәһәрләрдә яшәүчеләр тоячак. Анда коммуналь хезмәтләр өчен бәяләр 12 процентка кадәр күтәрелде. Республика районнарының күбесендә әлеге күрсәткеч 9 проценттан артмый. Аның каравы киләсе 1,5 елда ТКХ бәяләре үзгәрмәскә тиеш. Гыйнварда киләчәк түләү кәгазьләрендә нинди суммалар күтәргә? Газ, ут һәм су өчен кемнәргә ташламалар тиеш? «ВТ» әнә шул сорауларга ачыклык кертергә тырышты.**

> 5

### Ишетми калмагыз

Мәскәү белән Казанны тоташтырачак түләүле М12 юлында быелга асфальт салу планы үтәлгән. Россия вице-премьеры Марат Хөснуллин әйтүенчә, юлның 570 чакрымы, ягъни 70 проценттан артыграк өлеше дигән сүз бу. Юл түшәмәсенә барлыгы 5,8 миллион тоннадан артыграк асфальт-бетон тотылган. 48 чакрым озынлыктагы өлешендә автомобильләр йөри дә икән инде. Киләсе елда трасса төзелеп бетәргә тиеш. Татарстанда ул Кайбыч, Апас, Югары Ослан, Лаеш һәм Питрәч районнары аша уза.

Татарстан ВИЧ-инфекция уртача дәрәҗәдә таралган төбәкләр исәбенә керә. Роспотребнадзор идарәсе белгече Луиза Борисова әйтүенчә, 10 айда чир таралу күрсәткече 100 мең кешегә 167 очрак булган. Россия буенча уртача күрсәткечтән ике тапкыр кимрәк бу. 1 ноябрьгә республикада 15 меңгә якын кеше ВИЧ буенча исәптә тора.

Декабрь аенда кайбер төбәкләрдә, шул исәптән Татарстанда һава температурасы нормадан түбәнрәк булачак. Карның бик аз һәм сирәк явуы көтелә. Россия Гидрометеорология үзәге җитәкчесе Роман Вильфанд сөйләп үткәнчә, Үзәк һәм Идел буе федераль округларында нормадан тайпылыш күзәтеләчәк.

Республикада ял көннәрендә суыта. Шимбә – 3 декабрьдә көндез –12...–17 градус булса, төнлә термометрның терекөмеш баганасы –16...–21, урыны белән –27 градуска кадәр төшәчәк. Якшәмбе – 4 декабрьдә көндез –12...–17, төнлә –19...–24 градус. Явым-төшем юк диярлек. Башлангыч фаразларга караганда, киләсе атна башы – 5–6 декабрьдә көнчыгыш районнарда аз гына кар явып узачак. Көндез –8...–13, төнлә –13...–18 градус булыр дип көтелә.


## Сөенечле хәбәр!

**2022 елның 5–15 декабрь көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылыш була!**

**П2435** җомга саны — **Ташламалы бәя** 444 сум 54 тиен; гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~

**П2409** атнага дүрт тапкыр чыга — **Ташламалы бәя** 980 сум 10 тиен; гадәти бәясе – ~~1143 сум 96 тиен~~

Реклама 16+

# УТТАН АЛЫП, СУГА САЛМА...

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Бу айдан ут, газ, җылылык, су, пычрак суларны агызу һәм каты көнкүреш калдыкларын чыгарган өчен кыйммәтрәк түли башларга туры киләчәк. 1 декабрьдән ил күләмендә коммуналь хезмәтләргә бәяләр артты. «Очрашу өчен бик күңелле сәбәп түгел, – дип башлады сүзен тарифлар үсүгә багышланган чарада Татарстанның Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе Александр Груничев. – Тарифларны арттыруның чираттагысы киләсе елның 1 июлендә генә көтелсә дә (ә бәяләр гадәттә елга бер тапкыр үсә), ил Хөкүмәте карары нигезендә әлеге чара быел 1 декабрьгә күчерелде». Шул рәвешле, бер ел эчендә икенче тапкыр коммуналь хезмәтләргә бәяләр арта.

Ничарадан бичара дигәндәй, моның котылгысыз адым икәнен дә ассызыклады Александр Груничев. Аның сүзләренә караганда, бу халыкка өзлексез хезмәт күрсәтү өчен кирәк. Бүген республикадагы инженер челтәрләренең өчтән бер өлеше тузган. Татарстанда 5 мең 900 чакрым озынлыкта су үткәрү, 1 мең чакрымнан артык озынлыкта җылылык челтәрен алмаштырырга кирәк. Александр Груничев тынычландырырга да ашыкты: коммуналь хезмәтләр өчен бәяләр 2024 елның җәенә кадәр кабат артмаячак. Шулай итеп, ел ярым дәвамында кыйммәтләнмәячәк.

**«Аптырап китмәгез!»**

Яңача исәпләнгән коммуналь түләү кәгазьләрен киләсе елның гыйнварында алачакбыз. Декабрь өчен исәп-хисап шул айда ясала. Республика күләмендә бәяләр уртача 9 процентка артты. Казанда, мәсәлән, тарифлар күп дигәндә 10 процентка күтәреләчәк. Ут-суга түләүләр артуны баюннан да бигрәк Чаллы, Бөгелмә, Түбән Кама, Иннополис, Азнакай, Арча, Баулы, Яшел Үзән һәм Зәй шәһәрләре халкы тоячак. Аларда бәяләр 12 процентка кадәр үсәргә мөмкин. Бу исемлектә республиканың шәһәр тибындагы ун бистәсе һәм ун авылы да бар. «Бирегә халыкка хезмәт күрсәтүне федераль канунннар белән тәңгәлләштерергә кирәк», – дип аңлатты комитет рәисе. Кыскасы, ут янсын, су аксын өчен күбрәк түләргә туры киләчәк.

Татарстан төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасары Алексей Фролов, яңа түләү кәгазьләрен алгач, артык аптырап китмәскә дә киңәш итте. «Кышкы чорда болай да күп түлибез. Коммуналь түләү кәгазьләренә җылылык өчен шактый акча өстәлә. Шуны да истән чыгармагыз», – диде ул. Ут, газ һәм каты көнкүреш калдыкларын чыгару өчен түләү бөтен республика өчен бер үк. Ә менә җылылык һәм су белән тәэмин итү, пычрак суны чыгарган өчен түләү кайда яшәүгә карап аерыла. Яңа бәяләргә аерым тукталыйк.

**БЫЕЛ ГАЗ ҺӘМ УТКА БӘЯЛӘР НИЧЕК КҮТӘРЕЛДЕ?**

| | | 1 июль | 1 декабрь | арту (%) |
|---|---|---|---|---|
| Газ (сум/куб.метр) | | 6,25 | 6,78 | 8,5 |
| Ут (сум/кВт/сәгать) | Шәһәр (газ плитәсе) | 4,30 | 4,68 | 9 |
| | Шәһәр (электр плитәсе) | 3,20 | 3,58 | 11,9 |
| | Авыл | 3,01 | 3,28 | 9 |

**УТ.** 1 декабрьдән республикада яшәүчеләр өчен электр энергиясенең бәясе, өстәмә кыйммәткә салымны исәпкә алып, бер кВт/сәгатькә 4 сум 68 тиен тәшкил итте. Электр плитәләре яки электр җылыту җайланмалары булган йортларда яшәүчеләр өчен ул бер кВт/сәгатькә – 3 сум 58 тиен, ә авылда яшәүчеләр өчен – 3 сум 28 тиен. Ике тарифлы исәпләгечләр урнаштырылган очракта, тариф төрлечә булачак, дип аңлаттылар.

**ГАЗ ҺӘМ ҖЫЛЫЛЫК.** «Зәңгәр ягулык» 53 тиенгә кыйммәтләнгән. Хәзер аның бер куб метры 6 сум 78 тиен тәшкил итә. Бәяләр халык өчен дә, сәнәгать оешмалары өчен дә артты. Монополиягә каршы федераль хезмәт карары нигезендә, 1 декабрьдән илдә газны күпләп сату, аны күчерү хезмәтләре өчен тарифлар 8,5 процентка кыйммәтләнгән. Шуңа күрә халыкка сатыла торган ягулык бәясен дә яңадан исәпләргә туры килгән. «Газ кыйммәтләнгәч, җылылыкка бәя артачагы да көн кебек ачык. Үсеш 7 процент тәшкил итте. Бернишләтеп тә булмый. Җылылык өчен бәя артык күтәрелмәсен өчен, хәлдән килгәннең барын да эшләдек», – диде Александр Груничев.

**СУ.** Тариф кайсы оешма хезмәт күрсәтүенә карап аерыла. Мәсәлән, башкала халкы су өчен 2 сум 60 тиенгә кыйммәтрәк түли башлаячак. Аның бер куб метры 27 сум 36 тиенгә җитәчәк. Пычрак суны агызган өчен 6 сумга күбрәк: бер куб метр өчен 33 сум 67 тиен акча чыгарып бирергә туры киләчәк. Әйтик, Чаллыда су – 2 сум 30 тиенгә (бер куб метры – 27 сум 44 тиен), пычрак су агызу – 1 сум 30 тиенгә (бер куб метры – 20 сум 42 тиен) кыйммәтләнәчәк. Түбән Кама халкына суның бер куб метры – 32 сум 10 тиенгә, ә пычрак суны агызуның бер куб метры 21 сум 76 тиенгә төшәчәк. Әлмәттә күрсәткечләр – 47 сум 80 тиен һәм 27 сум 56 тиен.

**БӘЯЛӘР ИҢ КҮП АРТКАН ШӘҺӘР ҺӘМ АВЫЛЛАР**

**9 шәһәр**

Азнакай ● Арча ● Баулы ● Бөгелмә ● Зәй ● Яшел Үзән ● Иннополис ● Чаллы ● Түбән Кама

**Шәһәр тибындагы 10 бистә**

Аксубай
Алексеевск
Җәлил
Карабаш
Тенеш
Карамалы Тау
Түбән Мактама
Балык Бистәсе
Урыссу
Кама Тамагы

**10 авыл җирлеге**


Красный Бор
Яңа Чишмә
Афанас
Кызыл Чишмә
Әбсәләм
Димтамак
Октябрьский
Осиново
Габишево
Комлы Кавал

**КАТЫ КӨНКҮРЕШ КАЛДЫКЛАРЫН ЧЫГАРУ.** Күпфатирлы йортларда яшәүчеләр өчен әлеге төр түләү 4 сумга артты һәм аена бер кешедән 103 сум 93 тиенгә җитте. Шәхси торак йортларда яшәүчеләргә исә хәзер ай саен җан башыннан 112 сум 74 тиен түләргә туры киләчәк.

Казан халкының коммуналь түләүләргә чыгымнары тагын да артмагае. Билгеле булганча, башкалада яшәүчеләргә кыш көне ишегалдындагы карны чыгарган өчен дә өстәп түли башларга тәкъдим иттеләр. Бәясен дә шактый саллы итеп куймакчылар. Александр Груничев тумаган тайның билен сындырмаска киңәш итте. «Ишегалдындагы карны түгү мәсьәләсе безнең комитетка карамый. Бу эшнең бәясе турында сөйләшергә иртәрәк әле. Иң әлек кар түккән өчен өстәмә түләү кирәкме-юкмы икәнен хәл итәсе бар. Әлеге карар фәкать күпкатлы йортларда яшәүчеләрнең ризалыгы белән генә кабул ителә ала», – диде ул.

Эльвира ВӘЛИЕВА

# КЕМГӘ НӘРСӘ ТИЕШ?



Илдар Мөхәммәтҗанов

Бәяләр болай тешләшкәндә, акчаны ничек тә янга калдыру җаен эзләргә кирәк, әлбәттә. Шундый юлларның берсе – коммуналь түләүләргә субсидия рәсмиләштерү, ягъни түләгән акчаның бер өлешен кире кайтару.

– Татарстанда халыкка ярдәм итү максатыннан, ташлама-субсидияләр бирү каралган. Мондый ярдәмгә социаль нормалар һәм нормативларны исәпкә алып, коммуналь хезмәтләр өчен түләү чыгымнары гомуми айлык керемнәренең 21 процентыннан артып киткән гаиләләр өмет итә ала. Субсидия рәсмиләштерү өчен, яшәү урыны буенча социаль яклау бүлекчәләренә мөрәҗәгать итәргә яки Дәүләт хезмәтләре порталы аша гариза җибәрергә кирәк. Агымдагы елның 11 аенда 73 мең гаилә матди ярдәм алган. Аларга 956 миллион сум акча түләнгән. 2023 елда әлеге максаттан 2 миллиард сум акча бүлеп биреләчәк, – диде Александр Груничев.

Субсидия ярты елга билгеләнә, аннары яңадан документлар тапшырырга кирәк. Акчалата ярдәмгә муниципаль яки дәүләт торагында яшәүчеләр, наем килешүе нигезендә фатир алып торучылар, торак кооперативы әгъзалары, фатир, шәхси йорт хуҗалары дәгъва кыла ала. Тагын бер шарт торакның мәйданына бәйле. Ул билгеләнгән стандартларга туры килергә тиеш. Әлеге күрсәткечне һәр төбәк үзе билгели. Татарстанда ул бер кешегә – 40 квадрат метр, ике кешелек гаиләдә җан башына – 23 квадрат метр, өч кешелек гаиләдә исә 17 квадрат метр тәшкил итә. Дәүләттән акчалата ярдәм алганны, керемнәрне раслап күрсәтергә туры киләчәк. Истә тотыгыз: коммуналь түләүләр буенча бурычлары булганнарга субсидия бирелми.

✓Биш көн яки аннан да күбрәк өйдә булмаган очракта, ут, су һәм газ өчен түләүне яңадан исәпләтергә дә мөмкин. Моның өчен командировкада яки ялда булуыңны дәлилләп күрсәтергә кирәк. Тик шунысы да бар: бу – техник сәбәпләр аркасында өйгә исәпләгечләр куйдырта алмаган кешеләргә генә кагыла.

✓Өч һәм аннан да күбрәк бала (шул исәптән уллыкка алган) тәрбияләүче гаиләләргә дәүләттән ярдәм бар. Аларга коммуналь түләүләргә киткән чыгымнарның өчтән бер өлешен кире кайтаралар.

✓Барлык төркем инвалидларга коммуналь хезмәтләр өчен түләгәндә ташламалар каралган. Наем нигезендә алынган торак өчен (күпфатирлы йорт булганда, аның белән идарә итү, йортның уртак милкен тәэмин итү, агымдагы ремонт өчен түләү), салкын, кайнар су, ут, җылылык өчен түләгәндә; үзәк җылыту системасы булмаган авыл өйләрендә, җылылык өчен тотылган чыгымнар өчен түләгәндә торак-коммуналь хезмәтләргә 50 процент ташлама бирелә.

✓Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар да коммуналь хезмәтләр өчен түләгәндә аның яртысы кадәр субсидия-ташламадан файдалана. Алга таба махсус хәрби операциядә катнашучылар, өйгә кайтканнан соң, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар исәбенә кертеләчәк һәм ташламалардан файдалана алачак дип тә көтелә. Исән-сау гына булсыннар! «Мобилизациягә китүчеләрнең гаилә әгъзаларына коммуналь түләүләр өчен субсидия-ташлама бирү каралмаган», – дип хәбәр иттеләр Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының матбугат хезмәтеннән.

«Коммуналь хезмәтләр өчен бәяләр сизелерлек артты, – диде Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе. – Без халыктан гел ризасызлык сүзләре ишетеп торабыз. Алга таба андыйлар тагын да күбәячәк. Тик төзекләндерү, ремонт эшләре кирәк дип чаң суккан оешма-предприятие җитәкчеләрен дә аңлап була. Шуңа күрә ике арада алтын урталыкны табарга кирәк». Чыгымнарны исәпләп тә күрсәтте ул. Казанда, мәсәлән, дүрт кешелек гаилә кышкы чорда коммуналь хезмәтләр өчен аена уртача 7 мең сум акча түли. Яңа елдан соң гаиләнең әлеге чыгымы якынча 700 сумга артачак. «Моннан да күпкә кыйммәтләнә икән, димәк, тикшерергә кирәк», – диде Александр Груничев. Көтәсе күп калмады...